ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 июнь, 2025 ел № 44/10

Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»» 2025 елның 20 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2015 елның 27 февралендәге 38/8, 2015 елның 9 ноябрендәге 3/5, 2017 елның 24 октябрендәге 20/6, 2018 елның 10 августындагы 26/10, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/12, 2019 елның 23 маендагы 31/8, 2020 елның 18 мартындагы 38/6, 2021 елның 4 августындагы 8/10, 2022 елның 2 ноябрендәге 17/10, 2023 елның 5 маендагы 23/10, 2023 елның 25 октябрендәге 27/11, 2024 елның 1 июлендәге 34/10 номерлы Карарлары редакциясендә) икенче абзацны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарлар, хосусыйлаштыру турында Федераль законның 13 статьясы 1 пункты 1, 1.1, 5, 9 һәм 10 пунктчаларында каралган ысуллар белән гамәлгә ашырыла торган муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарлардан тыш, кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтта ачык файдалану мөмкинлегендә урнаштырылырга тиеш.».

2. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев